**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» октябрь 2019 с. Тюлячи № 587

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының
Мактау грамотасы турында

Теләче муниципаль районының гражданнарын, предприятие, учреждение, оешма, иҗтимагый оешмалар, шәхси эшмәкәрләрен социаль-икътисадый, мәдәни үсешкә зур өлеш керткәннәре, физик культура өлкәсендәге уңышлары өчен бүләкләү, аларның район алдындагы казанышларын тану, районның хезмәтендә һәм иҗтимагый тормышында активлыгын стимуллаштыру максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Мактау грамотасы турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«23» 10 20__ ел № 587
номерлы карарына
кушымта

**Нигезләмә**
**Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының**
**Мактау грамотасы турында**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Мактау грамотасы (алга таба текст буенча - Грамота) район үсешенә, хезмәттәге казанышларны, һөнәри осталыкны, фәнни һәм иҗади эштәге казанышларны тануга, укуда, тәрбия һәм башка иҗтимагый-файдалы эшчәнлектә уңышларга ирешүгә кагылышлы документаль таныклык булып тора.

1.2. Грамота белән районның барлык тармакларында, социаль-мәдәни өлкәдә эшләүче вазифаи затлар, эшчеләр, инженер-техник хезмәткәрләр, студентлар, мәгариф, фән, сәнгать, әдәбият һәм башка өлкә хезмәткәрләре, сугышчылар һәм ветераннар, хезмәт коллективлары (бригадалар, экипажлар, сменалар, төркемнәр, предприятие, оешма, учреждениеләр һ.б.) бүләкләнә.

1.3. Хезмәт коллективы яки конкрет затны бүләкләү предприятие, оешма һәм учреждение хезмәт коллективлары тәкъдиме (үтенечнамәсе) буенча башкарыла.

1.4. Грамота белән бүләкләүгә Теләче муниципаль районы башлыгы, Башкарма комитет, предприятие, оешма-предприятиеләрдән Рәхмәт хаты алган кешеләр хокуклы. Грамота белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә җитәкче кул куйган характеристика, гражданин паспортының күчермәсе, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелергә тиеш. Предприятие, учреждение һәм оешмаларның җитәкче составы затларын, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, тапшырганда, күрсәтелгән документлардан тыш, предприятиенең, учреждениенең, оешманың социаль-икътисади хәле, соңгы өч елда төп финанс-икътисадый күрсәткечләр динамикасы турында белешмәләр дә бирелергә тиеш (белешмәләрнең гамәлдә булу вакыты - 3 ай).

1.5. Бүләкләү турындагы хәбәр Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына бүләкләү датасына кадәр бер ай кала кертелә.

1.6. Грамота белән бүләкләү турындагы карар Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә, ул массакүләм мәгълүмат чараларында яки Теләче муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыга.

1.7. Грамота тексты ике дәүләт телендә (татар һәм рус) рәсмиләштерелә һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы текстына туры килергә тиеш.

1.8. Бүләкләнүчегә грамота тапшыруны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе яки аның вәкаләтле вәкиле тантаналы шартларда башкара.

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе кушуы буенча һәм аның исеменнән грамотаны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары тапшыра алалар.

1.9. Бүләкләнүчедән район Мактау грамотасын тартып алу, район бүләкләре буенча комиссия тәкъдиме нигезендә, тиешле нигезләнгәннән (дөреслек, нигезсез бүләкләү яки башка сәбәпләр аркасында бүләкләү) соң башкарылырга мөмкин. Тартып алу турында карар Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

1.10. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән батырлык, кыюлык, батырлык һәм кыюлык күрсәткәннәре, район файдасына башкарылган аерым бер очрак өчен бүләкләүдән тыш, алдагы бүләкләүдән соң 3 елдан да соңга калмыйча район алдында яңа казанышлар өчен Мактау грамотасы белән бүләкләнү мөмкин.

1.11. Мактау грамотасы югалганда дубликат бирелми.

1.12. Район Мактау грамотасы белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе башкара.